**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5631**
**31.10.2019**

«2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасы турында

Яр Чаллы шәһәре халкы сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен шартлар тудыру һәм җәмгыятьнең төрле катлауларын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү максатында, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

«2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә физик культура һәм спортны үстерү муниципаль программасын тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Физик культура» 1101 һәм «Массакүләм спорт» 1102 бүлекләрендә (бүлекчәләрендә) каралган акчалар хисабына 1 481 938,61 мең сум: 2020 елда – 529 255,05 мең сум, 2021 елда – 476 341,78 мең сум, 2022 елда – 476 341,78 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 31 октябрендәге
5631 нче карарына
кушымта

1 бүлек. «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасының паспорты

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Программаның исеме | «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль ерәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасы (алга таба – Программа) | | | | |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 159 нчы карары белән расланган «2019-2022 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы | | | | |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | | | | |
| Программаны үтәүчеләр | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре | | | | |
| Программаның максаты | Халыкның төрле катлауларын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү | | | | |
| Программаның бурычлары | 1. Халыкны физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү дәрәҗәсен арттыру.<br>2. Югары казанышлар спортын үстерү. Спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру | | | | |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 1 этап – 2020 ел,<br>2 этап – 2021 ел,<br>3 этап – 2022 ел | | | | |
| Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары (тыс. руб.) | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
| | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 529 255,05 | 476 341,78 | 476 341,78 | 529255,05 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 529 255,05 | 476 341,78 | 476 341,78 | 529255,05 |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2022 елга түбәндәгеләр күздә тотыла:<br>1) физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче гражданнар өлешен гомуми халык санының 49% ына кадәр арттыру;<br>2) физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар өлешен әлеге категориядәге халыкның гомуми санының 21% ына кадәр арттыру;<br>3) ГТО БФСК нормативларын үтәгән халык өлешен ГТО БФСК үтәүдә катнашкан халыкның гомуми санының 37% ына кадәр арттыру;<br>4) спортчыларның спорт төрләре буенча республика, бөтенроссия һәм халыкара ярышларда алга таба да катнашуына ярдәм итү |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Программаның үтәлешенә контрольне Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе гамәлгә ашыра |

2 бүлек. Программаны раслау кирәклеге турында аңлатма язуы

Яр Чаллы шәһәренең социаль-икътисадый проблемаларын хәл итү контекстында физик культура һәм спортны үстерү сәламәтлекне ныгыту, эшкә сәләтлелекне арттыру, халыкның озын гомерле булуын арттыру, халыкның сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру өчен мөһим ресурс буларак карала. Халык сәламәтлеген билгели торган мөһим фактор булып Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче һәр кешенең бөтен гомере дәвамында оптималь физик активлыкны саклап калу тора. Тәҗрибә күрсәткәнчә, муниципаль программаны тормышка ашырганда бурычлар хәл ителергә мөмкин.

Моннан тыш, Яр Чаллы шәһәренең киң халык массасын физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, халыкның сәламәтлек торышы, шәһәр, республика, Россия, халыкара дәрәҗәдәге ярышларда ирешкән уңышлар шәһәрнең спорт имиджын алга этәрүдә бәхәссез дәлил булып тора.

Максатчан программа методының төп өстенлекләре:

1) проблеманы хәл итүгә комплекслы якын килү;

2) вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлү;

3) программаны тормышка ашыру йомгакларын нәтиҗәле планлаштыру һәм мониторинглау.

Барлык программа чараларын уңышлы тормышка ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

- Яр Чаллы шәһәренең физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче, шул исәптән сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикле кешеләре санын арттырырга;
- спорт резервы һәм югары класслы спортчылар әзерләргә;
- физик культура һәм спорт тармагы хезмәткәрләренең һөнәри компетентлыгын арттырырга;
- шәһәрнең спорт имиджын күтәрергә;
- физик культураны һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау системасын оештырырга.

Бары тик сәламәт, оптимистик рухлы, психологик яктан тотрыклы, акыл һәм физик эшчәнлеге югары дәрәҗәдәге сәламәт кеше генә актив яши, төрле кыенлыкларны уңышлы җиңә һәм җәмгыятькә файда китерә ала.

Шулай итеп, физик культура һәм спортны үстерү – нәтиҗәле социаль сәясәтнең иң мөһим бер өлеше.

### 3 бүлек. Әлеге программаның төп максатлары, бурычлары. Аны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары

Программаның максаты булып җәмгыятьнең төрле катлауларын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге төп бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. Халыкны физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү дәрәҗәсен арттыру.

2. Югары казанышлар спортын үстерү. Спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру.

Әлеге бурычларны хәл итү «Физкультура-спорт чаралары» һәм «Спортны үстерү буенча чаралар» юнәлешләре буенча Программага керә торган чаралар кысаларында гамәлгә ашырылачак.

Программаны тормышка ашыру 3 елга (2020-2022 еллар) исәпләнгән һәм 3 этапта гамәлгә ашырылачак.

1 этап (2020 ел) түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) физкультура-спорт оешмаларын ирекле сертификацияләүне уздыру;

2) физик культура һәм спорт белгечләренең квалификациясен күтәрүне тәэмин итү;

3) Хаким стипендияләрен һәм югары квалификацияле спортчыларны бер тапкыр бирелә торган бүләкләү юлы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә талантлы укучыларга ярдәм күрсәтү;

4) яшәү урыны буенча балалар, яшүсмерләр, студентлар, гаилә, ветераннар спортын, физик культураны үстерү чараларын гамәлгә ашыру;

5) сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар өчен чаралар үткәрү;

6) массакүләм мәгълүмат чаралары һәм интернет-ресурслар аша физик культура һәм спортны пропагандалауны көчәйтү;

7) югары квалификацияле спортчыларның тренировка процессын материаль-техник, методик һәм программа белән тәэмин итү;

8) дәүләт-шәхси партнерлыкны җәлеп итеп, спорт инфраструктурасын үстерү.

Беренче этап дәвамында түбәндәгеләр планлаштырыла:

- Яр Чаллы шәһәренең физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче гражданнарының өлешен 47,5 процентка кадәр арттыру;

- физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар өлешен әлеге категориядәге халыкның гомуми санында 19,5 процентка кадәр арттыру;

- ГТО БФСК нормативларын үтәгән халык өлешен ГТО БФСК үтәүдә катнашкан халыкның гомуми санында 35,5 процентка кадәр арттыру.

2 этап (2021 ел) түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) физкультура-спорт оешмаларын ирекле сертификацияләүне уздыру;

2) физик культура һәм спорт белгечләренең квалификациясен күтәрүне тәэмин итү;

3) Хаким стипендияләрен һәм югары квалификацияле спортчыларны бер тапкыр бирелә торган бүләкләү юлы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә талантлы укучыларга алга таба да ярдәм күрсәтү;

4) физик культура һәм спортны пропагандалау чараларын гамәлгә ашыру;

5) яшәү урыны буенча балалар, яшүсмерләр, студентлар, гаилә, ветераннар спортын, физик культураны үстерү чараларын гамәлгә ашыру;

6) сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар өчен чаралар үткәрү;

7) югары квалификацияле спортчыларның тренировка процессын материаль-техник, методик һәм программа белән тәэмин итү.

Икенче этап дәвамында түбәндәгеләр планлаштырыла:

- Яр Чаллы шәһәренең физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче гражданнарының өлешен 48,5 процентка кадәр арттыру;

- физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар өлешен әлеге категориядәге халыкның гомуми санында 20,5 процентка кадәр арттыру;

- ГТО БФСК нормативларын үтәгән халык өлешен ГТО БФСК үтәүдә катнашкан халыкның гомуми санында 36,5 процентка кадәр арттыру.

3 этап (2022 ел) түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) физкультура-спорт оешмаларын ирекле сертификацияләүне уздыру;

2) физик культура һәм спорт белгечләренең квалификациясен күтәрү буенча алга таба эш;

3) Хаким стипендияләрен һәм югары квалификацияле спортчыларны бер тапкыр бирелә торган бүләкләү юлы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә талантлы укучыларга алга таба да ярдәм күрсәтү;

4) физик культура һәм спортны пропагандалау чараларын гамәлгә ашыру;

5) яшәү урыны буенча балалар, яшүсмерләр, студентлар, гаилә, ветераннар спортын, физик культураны үстерү чараларын гамәлгә ашыру;

6) сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар өчен чаралар үткәрү;

7) югары квалификацияле спортчыларның тренировка процессын материаль-техник, методик һәм программа белән тәэмин итү.

Өченче этап дәвамында планлаштырыла:

- Яр Чаллы шәһәренең физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче гражданнарының өлешен 49,0 процентка кадәр арттыру;

- физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар өлешен әлеге категориядәге халыкның гомуми санында 21,0 процентка кадәр арттыру;

- ГТО БФСК нормативларын үтәгән халык өлешен ГТО БФСК үтәүдә катнашкан халыкның гомуми санында 37 процентка кадәр арттыру;

- спорт төрләре буенча бөтенроссия һәм халыкара ярышларда чыгыш ясаучы спортчылар өлешен саклап калу.

## 4 бүлек. Программа чараларының исемлеге

Программа чараларының исемлеге әлеге Программаның 8 бүлегендә күрсәтелгән.

Халыкны физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү дәрәҗәсен арттыру өлешендә түбәндәгеләр күздә тотыла:

1) төрле яшь категорияләре арасында спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар, массакүләм ярышлар үткәрү;

2) «Сабан туе» халык бәйрәме кысаларында спорт төрләре буенча милли халык уеннары һәм ярышлар үткәрү;

3) спорт төрләре буенча хезмәт ияләре Спартакиадасы үткәрү;

4) спорт чараларының еллык календаре нигезендә спортның 8 төре буенча «Физик мөмкинлекләре чикле кешеләр арасында Яр Чаллы шәһәре мэры Кубогы»на ярышлар үткәрү.

Югары казанышлар спортын үстерү буенча чаралар. Спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру түбәндәгеләрне күздә тота:

1) шәһәр Хакиме стипендияләрен түләү юлы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә талантлы укучыларга ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

2) муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләре арасыннан шәһәр Хакиме премиясен алу өчен кандидатларны сайлап алу;

3) халыкара һәм бөтенроссия ярышларында югары спорт казанышлары өчен спортчыларга бер тапкыр бирелә торган түләү;

4) спорт резервы һәм югары класслы спортчылар әзерләү;

5) заманча спорт-сәламәтләндерү комплексы, махсуслаштырылган спорт корылмасы төзү.

## 5 бүлек. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары

Программаны тормышка ашыруның арадаш һәм ахыргы нәтиҗәләрен бәяләү өчен нәтиҗәлелекне бәяләүнең түбәндәге индикаторлары файдаланыла:

| Т/с | Индикаторның исеме | Исәпләү методикасы | Чыганак |
|---|---|---|---|
| 1 | Физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче халык өлеше, Яр Чаллы шәһәренең 3 яшьтән һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге халкының гомуми санында, % | Дз = Чз / Чн х 100, монда:<br>Дз – физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче шәһәр халкының чагыштырма авырлыгы,<br>Чз – физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр саны;<br>Чн – статистика мәгълүматлары буенча халык саны | «Физик культура һәм спорт турында мәгълүматлар» №1-ФК формасы буенча статистик күзәтү мәгълүматлары |
| 2 | Физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар өлеше, халыкның әлеге категориясендәге гомуми санда, % | Ди = Чзи /Чни х 100, монда:<br>Ди – физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче физик мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар өлеше;<br>Чзи – физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче физик мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар саны;<br>Чни – мөмкинлекләре чикле халык һәм инвалидлар саны | «Адаптив физик культура һәм спорт турында мәгълүматлар» №3-АФК формасы буенча статистик күзәтү мәгълүматлары |
| 3 | «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәгән халык өлеше, ГТО нормативларын үтәүдә катнашкан халыкның гомуми санында, % | Дв=Чв / Чп х 100, монда:<br>Дв – ГТО нормативларын үтәгән халык өлеше;<br>Чв – ГТО нормативларын үтәгән затлар саны;<br>Чп – ГТО үтәүдә катнашкан халык саны | Шәһәр халкының ГТО нормативларын үтәү беркетмәләре |
| 4 | Спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар, массакүләм ярышлар, берәмлек | N – сан | Башкарма комитетның спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар, массакүләм ярышлар оештыру һәм үткәрү турында карарлары |
| 5 | «Сабан туе» халык бәйрәме кысаларында ярышлар саны, берәмлек | N – сан | Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәрендә «Көрәш» татар-башкорт көрәше, армспорт, гер спорты, авыр атлетика, шахмат, ат спорты, җиңел атлетика йөгерүе, волейбол, халык-милли уеннары һәм узышлар буенча ярышлар оештыру һәм үткәрү турында» |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | карары |
| 6 | «Спорт сөюче Чаллы» спартакиадасы кысаларында үткәрелгән спорт төрләре буенча ярышлар саны, берәмлек | N – сан | Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәрендә «Спорт сөюче Чаллы» хезмәткәрләр спартакиадасы үткәрү турында» карары |
| 7 | «Физик мөмкинлекләре чикле кешеләр арасында Яр Чаллы шәһәре Хакиме Кубогы»на ярышлар, берәмлек | N – сан | Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәрендә инвалидлар һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар арасында спорт төрләре буенча Хаким Кубогына ярышлар оештыру һәм үткәрү турында» карары |
| 8 | Хаким стипендиясен алган балалар һәм яшүсмерләр саны, кеше | N – сан | Шәһәр Хакименең «Сәнгать, спорт һәм иҗтимагый эшчәнлек өлкәсендә Яр Чаллы шәһәре Хакименең исемле стипендияләрен билгеләү турында» карары |
| 9 | Хаким премиясен алган муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләре саны, кеше | N – сан | Шәһәр Хакименең «Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренә Яр Чаллы шәһәре Хакиме премияләрен билгеләү турында» карары |
| 10 | Россия, Европа, Дөнья чемпионатлары, Олимпия уеннары, Бөтендөнья Универсиадасы җиңүчеләре һәм призерлары саны, кеше | N – сан | Башкарма комитетның «Халыкара һәм бөтенроссия ярышларында ирешкән уңышлары өчен спортчыларга бер тапкыр бирелә торган түләү турында» карары |
| 11 | Тренерларның гомуми саныннан югары һөнәри белемле тренер кадрларының өлеше, % | А /В х 100, монда:<br>А – югары һөнәри белемле тренер кадрлары саны;<br>В – тренерларның гомуми саны | Физик культура һәм спорт учреждениеләре тарафыннан муниципаль йөкләмәләр үтәлеше турында хисап |
| 12 | Төркемнәрнең хезмәт күрсәтү сыйфатыннан фактта тулылыгы, % | А /В х 100, монда:<br>А – төркемнәрнең фактик тулылыгы;<br>В – төркемнәрнең норматив тулылыгы | |
| 13 | Конкурсларда, фестивальләрдә, күргәзмәләрдә, ярышларда катнашучы шөгыльләнүчеләрнең шөгыльләнүчеләр санындагы өлеше,%, шул исәптән:<br>- муниципаль;<br>- региональ;<br>- федераль;<br>- халыкара | А /В х 100, монда:<br>А – конкурсларда, фестивальләрдә, күргәзмәләрдә, ярышларда катнашучы шөгыльләнүчеләр саны;<br>В – шөгыльләнүчеләрнең гомуми саны | |
| 14 | Тренировка программаларын үтәү проценты, % | А /В х 100, монда:<br>А – программа буенча үткәрелгән сәгатьләр саны;<br>В – программада каралган сәгатьләр саны | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 15 | Контингент сакланышы, % | C=Укуг / Унуг х 100, монда:<br>C – контингент сакланышы;<br>Укуг – тренировка елы ахырына шөгыльләнүчеләр саны;<br>Унуг – тренировка елы башына шөгыльләнүчеләр саны | |
| 16 | Заманча спорт-сәламәтләндерү комплексы, махсуслаштырылган спорт корылмасы, объектлар төзелеше | N – төзелгән корылмалар саны | «Физик культура һәм спорт турында мәгълүматлар» № 5-ФК формасы буенча статистик күзәтү мәгълүматлары |

## 6 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программа чараларын тормышка ашыру өчен 1 481 938,61 мең сум: 2020 елда – 529 255,05 мең сум, 2021 елда – 476 341,78 мең сум, 2022 елда – 476 341,78 мең сум күләмендә муниципаль бюджет акчаларыннан файдалану күздә тотыла.

## 7 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Физик культура һәм спорт идарәсе, муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре үз компетенциясе чикләрендә программа чараларын тормышка ашыру өчен шартлар тудыралар.

Программаны тормышка ашырудан социаль-икътисадый нәтиҗәлелек түбәндәгеләр хисабына ирешелә:

1) Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче кешеләр өлешен арттыру;

2) бөтенроссия һәм халыкара ярышларда шәһәр спортчылары ирешкән нәтиҗәләрне үстерү;

3) физик культура һәм спорт тармагы хезмәткәрләренең һөнәри компетентлыгы дәрәҗәсен күтәрү;

4) оештырылмаган төркемдәге балаларны һәм яшьләрне спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү;

5) мөмкинлекләре чикле кешеләрне физик тернәкләндерү һәм социаль адаптацияләү өчен мөмкинлекләрне киңәйтү;

6) ялның сәламәтләндерүче актив формаларында шәһәр халкы ихтыяҗларын канәгатьләндерү.

## 8 бүлек. Программа чаралары

| Т/с | Программа чараларының исеме | Финанслау чыганаклары | Финанслау күләме, шул исәптән сроклар буенча | | | | Программа чараларын башкаручылар | Сан ягыннан көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы, мең сум | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Массакүләм спорт | | | | | | | | |
| Физкультура-спорт чаралары | | | | | | | | |
| 1 | Төрле яшь категорияләре арасында спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар үткәрү<br>Төрле яшь категорияләре арасында спорт төрләре буенча массакүләм спорт ярышлары үткәрү | муниципаль берәмлек бюджеты | 4346,4 | 1440,4 | 1453 | 1453 | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе (алга таба - Физик культура һәм спорт идарәсе) | Пропагандалауны оештыру буенча чараларны гамәлгә ашыру, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче халык санын арттыру |
| 2 | «Сабан туе» халык бәйрәме кысаларында спорт төрләре буенча ярышлар, милли халык уеннары һәм ярышлары үткәрү | муниципаль берәмлек бюджеты | 3 000,0 | 1 000,0 | 1 000,0 | 1 000,0 | Физик культура һәм спорт идарәсе | Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче халык санын арттыру |
| 3 | «Спорт сөюче Чаллы» хезмәт ияләре спартакиадасы үткәрү | муниципаль берәмлек бюджеты | 148,5 | 49,5 | 49,5 | 49,5 | Физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау,<br>физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче халык санын арттыру |
| 4 | «Физик мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме Кубогы»на ярышлар үткәрү | муниципаль берәмлек бюджеты | 95,4 | 31,8 | 31,8 | 31,8 | Физик культура һәм спорт идарәсе | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, халыкның төрле категорияләре өчен зур мөмкинлекләр тудыру |
| Балалар-яшүсмерләр спортын үстерү буенча чаралар | | | | | | | | |
| 5 | Шәһәр Хакиме стипендияләре түләү юлы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә талантлы укучыларга ярдәм күрсәтү | муниципаль берәмлек бюджеты | 360,0 | 120,0 | 120,0 | 120,0 | Физик культура һәм спорт идарәсе | Талантлы яшьләрне спорт белән регуляр шөгыльләнүгә стимуллаштыру |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Югары һөнәри осталык өчен муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләре өчен Хаким премиясен гамәлгә кую | муниципаль берәмлек бюджеты | 1347,0 | 449,0 | 449,0 | 449,0 | Физик культура һәм спорт идарәсе | Физкультура-спорт юнәлешендәге квалификацияле хезмәткәрләр санын арттыру |
| 7 | Халыкара һәм Россия ярышларында югары спорт казанышлары өчен спортчыларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү | муниципаль берәмлек бюджеты | 3 701,7 | 1 233,9 | 1 233,9 | 1 233,9 | Физик культура һәм спорт идарәсе | Төрле дәрәҗәдәге ярышларда яуланган призлы урыннар санын арттыру |
| 8 | Массакүләм спорт бүлеге буенча БАРЛЫГЫ | муниципаль берәмлек бюджеты | 12 999,0 | 4 324,6 | 4 337,2 | 4 337,2 | | |
| 9 | Түбәндәге спорт төрләре буенча спорт әзерлеге программасын гамәлгә ашыру: баскетбол, волейбол, җиңел атлетика, спорт ориентлашуы, дзюдо, каратэ киокусинкай, кикбоксинг, йөзү, синхрон йөзү, нәфис гимнастика, велоспорт, спорт гимнастикасы, теннис, тимераякта узышу спорты, футбол, велоспорт (шоссе), регби, билбаулы көрәш, грек-рим көрәше, армреслинг, көрәш, йөзү, тхэквондо, күп стильдәге каратэ, батутта сикерү, АКД, спорт акробатикасы, бокс, авыр атлетика, чаңгы узышлары, бию спорты, ат спорты, спорт туризмы, өстәл теннисы, бадминтон, җилкәнле спорт, фехтование, пауэрлифтинг, алкалы хоккей, тимераякта фигуралы шуу, шахмат | муниципаль берәмлек бюджеты | 1418939,61 | 474 930,45 | 472 004,58 | 472 004,58 | Муниципаль физкультура-спорт учреждениеләре | Спорт мәктәпләре һәм Олипия резервы спорт мәктәпләре эшен тәэмин итү |
| 10 | Заманча спорт-сәламәтләндерү комплексы, махсуслаштырылган спорт корылмасы төзелеше | муниципаль берәмлек бюджеты | 50 000 | 50 000 | - | - | Физик культура һәм спорт идарәсе | Спорт-сәламәтләндерү комплекслары, махсуслаштырылган спорт корылмалары төзелеше буенча дәүләт-шәхси партнерлыкта катнашу |
| | Программа буенча БАРЛЫГЫ | муниципаль берәмлек бюджеты | 1418939,61 | 529 255,05 | 476 341,78 | 476 341,78 | | |

## 9 бүлек. Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» программасы чаралары буенча финанслау

| Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү срогы | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | Чыганакны күрсәтеп, финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| Программаның максаты – җәмгыятьнең төрле катлауларын физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү | | | | | | | | | | |
| | | Физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче халык өлеше, гомуми халык саны буенча, % | 47,5 | 48,5 | 49,0 | | | |
| | | Физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар өлеше, халыкның әлеге категориясе саны буенча, % | 19,5 | 20,5 | 21 | | | |
| | | Физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәгән халык өлеше, ГТО үтәүдә катнашкан гомуми халык саны буенча, % | 35,5 | 36,5 | 37 | | | |
| Халыкны физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү дәрәҗәсен арттыру | Төрле яшь категорияләре арасында спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар үткәрү<br>Төрле яшь категорияләре арасында спорт төрләре буенча массакүләм спорт ярышлары үткәрү | Физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар, массакүләм ярышлар саны, берәмлек | 20 | 20 | 20 | 1440,4 | 1453 | 1453 |
| | «Сабан туе» халык бәйрәме кысаларында спорт төрләре буенча ярышлар, милли халык уеннары һәм ярышлары үткәрү | Физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | «Сабан туе» халык бәйрәме кысаларында ярышлар саны, берәмлек | 27 | 27 | 27 | 1000,0 | 1000,0 | 1000,0 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Спорт сөюче Чаллы» хезмәт ияләре спартакиадасы үткәрү | Физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | «Спорт сөюче Чаллы» спартакиадасы кысаларында спорт төрләре буенча ярышлар саны, берәмлек | 8 | 8 | 8 | 49,5 | 49,5 | 49,5 |
| | «Физик мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме Кубогы»на ярышлар үткәрү | Физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | «Физик мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме кубогы»на ярышлар саны, берәмлек | 8 | 8 | 8 | 95,4 | 31,8 | 31,8 |
| Югары казанышлар спортын үстерү. Спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру | Хаким стипендияләре түләү юлы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә талантлы укучыларга ярдәм күрсәтү | Физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Хаким стипендиясе алган балалар һәм яшүсмерләр саны, кеше | 10 | 10 | 10 | 120,0 | 120,0 | 120,0 |
| | Югары һөнәри осталык өчен муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләре өчен Хаким премиясе бирү | Физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Хаким премиясе алган физкультура-спорт учреждениеләренең хезмәткәрләре саны, кеше | 15 | 15 | 15 | 449,0 | 449,0 | 449,0 |
| | Халыкара һәм Россия ярышларында югары спорт казанышлары өчен спортчыларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү | Физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Россия, Европа, дөнья чемпионатларында, Олимпия уеннарында, Бөтендөнья Универсиадада бүләкләнгән җиңүчеләр һәм призерлар саны, кеше | 47 | 47 | 47 | 1 233,9 | 1 233,9 | 1 233,9 |
| | Түбәндәге спорт төрләре буенча спорт әзерлеге программасын гамәлгә ашыру: баскетбол, волейбол, җиңел атлетика, спорт ориентлашуы, дзюдо, каратэ киокусинкай, кикбоксинг, йөзү, синхрон йөзү, нәфис гимнастика, велоспорт, спорт гимнастикасы, теннис, тимераякта узышу спорты, футбол, велоспорт (шоссе), регби, билбаулы көрәш, грек-рим көрәше, | 17 муниципаль физкультура-спорт учреждениесе | ел саен | Гомуми тренерлар санынннан югары һөнәри белемле тренер кадрлар өлеше, % | 93 | 94 | 95 | 474930,45 | 472004,58 | 472004,58 |
| | | | | Хезмәт күрсәтү сыйфатына карап төркемнәрнең факттагы тулылыгы, % | 100 | 100 | 100 | | | |
| | | | | Конкурсларда, фестивальләрдә, күргәзмәләрдә, ярышларда катнашучы шөгыльләнүчеләр саны, гомуми укучылар саны буенча, %, шул исәптән:<br>- муниципаль;<br>- региональ;<br>-федераль, халыкара | <br><br><br><br><br>30<br>20<br>1 | <br><br><br><br><br>30<br>20<br>1 | <br><br><br><br><br>30<br>20<br>1 | | | |
| | | | | Укыту программаларының үтәлү проценты, % | 100 | 100 | 100 | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | армреслинг, көрәш, йөзү, тхэквондо, күп стильдәге каратэ, батутта сикерү, АКД, спорт акробатикасы, бокс, авыр атлетика, чаңгы узышлары, бию спорты, ат спорты, спорт туризмы, өстәл теннисы, бадминтон, җилкәнле спорт, фехтование, пауэрлифтинг, алкалы хоккей, тимераякта фигуралы шуу, шахмат | | | Контингент сакланышы, % | 88 | 88 | 88 | | | |
| | Заманча спорт-сәламәтләндерү комплексы, махсуслаштырылган спорт корылмасы төзелеше | Физик культура һәм спорт идарәсе | 2020 ел | Дәүләти-шәхси партнерлык катнашында төзелгән спорт-сәламәтләндерү комплекслары, махсуслаштырылган спорт корылмалары, берәмлек | 1 | | | 50 000 | | |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева